Әхмәтгалиева, А. "Ак калфак"ның яңарган чагы / А. Әхмәтгалиева // Сәхнә. – 2023. – №12 (216). – Б. 27-29.



# «АК КАЛФАК»НЫҢ ЯҢАРГАН ЧАГЫ

Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» драмасы — татар әдәбияты җәүһәрләренең берсе, театр тарихында аның үз урыны бар. Бу елның Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип исемләнүе нисбәтеннән, А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында шушы әсәр буенча премьера дөнья күрде.

Айгөл Әхмәтгалиева

Туры мәгънәдә татар хатын-кызларының баш киеме булган ак калфак — аклык-сафлык һәм намус символы ул. Спектакль аның аша хисләрнең яктылыгы һәм караңгылыгы, горурлык һәм тәкәбберлек, мәхәббәт һәм нәфрәт турында сөйли.

«Ак калфак» драмасы 1922 елда автор тарафыннан башта «Хәмдия» дигән исем белән языла. Бу хакта М. Фәйзи үз көндәлегендә: «Бер бүлекле «Хәмдия» дигән пьесамны тәгәлләдем», — дип белдерә. Пьеса ел дәвамында тулыландырыла, үзгәрешләр кичерә. 1923 елның 25 гыйнварында Нури Сакаев драманы Уфа сәхнәсендә куя, тик спектакль авторга ошамый: «Начар уйнадылар, киемнәр дә ошамады. Актрисадагы калфак кына ошады», — дип яза ул. Шуннан соң әсәргә тагын төзәтмәләр кертә һәм исемен «Ак калфак» дип үзгәртә. Димәк, «Ак калфак»ка — 100 яшь. Театрның сәнгать җитәкчесе, режиссёр Олег Кинҗәгуловны пьеса бүген кай ягы белән җәлеп иткән соң?

*— Бер гасыр узса да, пьесада күтәрелгән темалар шул ук бит. Совет заманында бар кеше дә тигез дип килсәләр дә, ул чакта социаль тигезлек булганмы? Бүген олигархларны һәм ярлыларны карагыз... Көтүче һәм морза кызы арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган гади бер мелодрама түгел бу, катлаулы, күпкырлы классик әсәр. Нинди генә персонажга, кайсы гына темага килеп тотынсаң да, бик кискен, актуаль сорауларга килеп чыгасың. Әйтик, Хәмдия үзе турында «мин мәзлумнарны яклаучы кыз», дисә дә, үз алдында конкрет максат куйган, шөһрәткә омтылу юлында үзалдына матур әкият тудырган («исемемә атап көй чыгаручы минем ярым булачак!»), минминлеге көчле персонаж. Үзе турында өченче заттан сөйләвенә генә игътибар итегез!.. Ирек сөям дигән Бакый да, бер мизгелдә күзләре кинәт «сукыраеп», кискен үзгәреш кичерә. Баш очында балта эленеп торганын бик яхшы аңлаган хәлдә, бай кызына мәхәббәт аңлатырга җөрьәт итә...*

Спектакльдә Бакый ролен Руслан Әюпов башкара. Актёрның сәхнә сөйкемлелеге, вокал мөмкинлеге драманың халыкчанлыгын, үлемсез җырларын һәр тамашачыга бөтен барлыгы белән җиткерә. Аның персонажы — гади көтүче булып кына калмыйча, морза улы Шаһтимер (Фердинант Насретдинов) авызыннан яңгыраган, «син бер асыл зат, ахры» дигән сүзләргә ияреп, үзенә читтән караган, каршылыклардан торган ир-егет. Пьесадагы вакыйгалар 1860



елда бара. Автор бу датаны махсус ассызыклап күрсәтә: тиздән, 1861 елда, император Александр II крепостное правоны бетерү турында манифестка кул куячак... Байларга, морзаларга бил бөгүче татар крестьяннары арасында да каршылык-лар көчәйгән чор бу. Кешеләрнең авыр тормыштан, кыерсытудан тәмам туйган, үз язмышлары турында уйлана башлаган чагы. Бакый кебек ир-егетләрдән салкын акыл, нык беләк, кайнар йөрәк таләп ителгән вакыт.

Пьесаның совет чорында, кызыл террор елларында язылуына игътибар итсәк, авторның морзаны һәм аның гаиләсен ни сәбәпле тискәре яктан күрсәтүе һәркемгә аңлашылыр. Сәхнәдә Сәлим морза (ТРның халык артисты Рафик Каюмов) М. Фәйзичә калса да, яңа табышлар ярдәмендә тамашачы аның күңеле нечкәргән мәлләрен дә күрергә өлгерә. Автор тарафыннан коточкыч дуамал, ярсу холыклы итеп сурәтләнгән морза, кечкенә Гали (Салих Сәхәбетдинов) белән уйнаган мәлендә үзе дә сабый балага әверелә дә куя. Ирен һәрдаим котыртып, ничек идарә итәргә кирәклеген өйрәтеп торган хатыны Җиһан (ТРның атказанган артисты Алсу Хәбетдинова) йөзендә исә матриархатның көче чагыла шикелле. Алай гына да түгел, Алсу уенында кеше холкының җетe төсмерләре тагын да калку итеп күрсәтелә. Үзе гел кыйналып, кимсетелеп яшәгән хатын янәшәдә башкаларның бәхетле көн күрүләрен күтәрә алмас иде, шуңа да ул әле бер, әле икенче хезмәтчене кыйнатудан тәм таба.

Чаллы театрында куелган спектакль кай ягы белән үзенчәлекле дигән сорауга режиссёрның төп җавабы — «Хәмдия турындагы стереотипларны җимердем», — ди ул.

Чыннан да, яшь артист Физәлия Габидуллина уенында Хәмдия һич кенә дә самими, хыялый бер кыз бала түгел. Автор теләгәнчә, әйе, аның бәхетле буласы килә, тик ул үзенә катлаулы каршылыклар уйлап чыгара. Тамашачы алдында — башкаларның хис-тойгылары белән идарә итүче, усал эти янында үсеп, үзе дә каты бәгырьлегә әйләнгән; әкияти, шул ук вакытта үзе өчен дә, башкалар өчен дә хөкем карары булачак теләгенә омтылган морза кызы.

Спектакльнең җан-йөрәге булган көйләр (композитор Гөлназ Закирова), сәхнәдәге нәфис бизәлеш (рәссам Ләйсән Хөсәенова), Алсу Гыйлманова, Рәзил Фәхертдинов, Юлия Григорьева уенындагы рәхәт табигыйлек, күмәк күренешләрдә мәктәп укучыларының да катнашуы – болар барысы да сәхнәдә барган вакыйгаларның тәэсир көчен арттыруга хезмәт итә.

Ялган горурлык һәм ялган тәкәбберлек, ике арадагы тирән упкын мәхәббәтне юк итәргә сәләтле.



**Ләйсән Хөсәенова,**
**рәссам:**

*— Декорацияне һич кенә дә көнкүреш тибында итеп эшлисе килмәде безнең, шартлылыкка таянырга булдык. Мәсәлән, берәм-берәм элеп куелган сарык бәрәннәре, игътибар белән караганда, бишек өстенә эленгән уенчыкларны хәтерләтә. Төш элементы дияргә була аларны: героиняның төшеме, фантазиясеме, әллә шул рухтагы башка бер әйберме... Вак-вак детальләр ярдәмендә вакыйгаларның су буенда яки морза өендә барганын күрсәтә алдык. Бакча урынын тасвирлаганда, янә шартлылыкка нигезләнгән, кан төсендәге кып-кызыл розаларны күрергә мөмкин иде. Декорациядә монументальлек өстенлек итте, шул ук ритмны костюмнарда да сакларга тырыштык: алар һич кенә дә йомшак, нәфис тукымалардан булмыйча, күн һәм тиредән иде.*



Мәхәббәт белән бергә моң да үлсә, ул моңнар кабат табылырмы? Репетицияләр барышында «Хәмдия» җырына бәйле рәвештә байтак сораулар туган иде. Бүгенге заманда моң төшенчәсенең югалып баруы, замана җилләренең ул моңнарны тузан урынына туздырырга маташуы хакында уртага салып сөйләшү сискәндереп җибәрде; Бакый белән бергә моң да үлеп юкка чыгармы дигән фикерләр булды. Спектакль азагында «Хәмдия» җырының кайтаваз булып яңгыравы исә — М. Фәйзи каләме белән язылып, морза кызы теленнән: «Илнең сезгер егетләре, назлы кызлары минем көемне җырлап яшь җаннарын юатырлар. Исемем телдән телгә, буыннан буынга күчеп мәңге яшәр», — дип тамган сүзләренең кайтавазы иде. Татарның ачы язмышында гомер бакый тугры юлдаш булган җыр бүгенгә исән бит әле, «Хәмдия»ләр булып моң яши бит әле бүген. Иртәгә ни булыр?..

Чаллы театры сәхнәсендәге «Ак калфак» әнә шундый сорауларга җавап эзләве белән үзенчәлекле.



**Олег Кинҗәгулов,**
режиссёр:

*— Балачактан ишеткән, җырланган «Хәмдия» җыры мәхәббәт турында түгел. Кешелеклелек хисе турында искәртү дияргә була аны. Күрә, ишетә, тоя белү, күңел киңлеге турында диимме... Комсызланып шөһрәткә омтылу бик аяныч нәтиҗәләргә китерә, героиняны да ярык тагарак янында утыртып калдыра...*




**Гөлназ Закирова,**
композитор:

*— «Ак калфак» — минем алтынчы премьерам, режиссёр Олег Кинҗәгулов белән өченче проектыбыз. Үзенчәлекле, матур куелыш булды ул. Бу әсәр 19 гасыр уртасындагы татар халкының көнкүрешен ачык күрсәтә. Борынгы, горур нәселне, Алтын Урдадан килгән гореф-гадәтләрне музыкамда үзенчәлекле итеп чагылдырырга тырыштым. Спектакльнең соңгы минутлары «җанландырылган фотография» эффектын хәтерләтте.*



**Зөлфирә Гыймадиева,**
тамашачы:

*— Һаман шул спектакль белән хисләнеп йөрим. Сәхнә бизәлеше, декорация, костюмнар — бар да искиткеч. Бакыйны уйнаган егетнең моңлы тавышын сокланып тыңладым. Андый моңлы тавышлар безнең эстрадада да бик сирәк. Актёрларның йөрәккә үтеп кереп уйнавы бигрәк тә ошады, тетрәндерде. Сәнгатькә сусап килгән тамашачы буларак бу спектакльдән үземә рухи азык алып кайттым. Нәкъ менә Хәмдия көйләре җитми бүген безгә. Шушы көйләрне халык күңеленә үтеп керерлек итеп башкара алучы артистларыбыз булганда, театрыбыз яшәр, үсәр, иншалла.*
*Хәзерге заманда узган гасырның бик җитди темасын кузгата алган яшь режиссёрның да киләчәге өметле күренә. Әсәрнең эчтәлеге нинди тирән мәгънәле булса, куелышы да профессиональ югарылыкта дип бәялим.*
*Афәрин, Чаллы театры!*



Фотолар А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының матбугат үзәгеннән алынды.